СОВЕТ
САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.07.2023 с. Сарсак-Умга авылы № 34-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннарны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 елның 498-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 15.05.2023 елның 02-06-2023/Прдп-207 номерлы күрсәтмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

*1) Сарсак-Умга авылының төньяк-көнчыгыш өлеше Яшьләр урамыннан 50 м ераклыкта;*

*2) Сарсак-Умга авылының көньяк-көнбатыш өлеше Ворошилов урамыннан 50 м ераклыкта.*

2. Йорт хайванын йөртү өчен түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

1) автомобиль юлының йөрү өлешен кичкәндә, күп фатирлы йортларның гомуми файдаланудагы биналарында, мондый йортларның ишегалларында, балалар һәм спорт мәйданчыкларында хайванның ирекле, контрольсез хәрәкәт итү мөмкинлеген булдырмаска;

2) гомуми файдаланудагы территорияләрдә һәм урыннарда хайваннар эшчәнлеге продуктларын җыюны тәэмин итәргә;

3) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитетының әлеге карары белән рөхсәт ителгән урыннардан читтә хайванны йөртүне булдырмаска

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Т.С. Николаева

Совет Сарсак-Омгинского сельского поселения Сарсак-Умга авыл җирлеге Советы ИНН 1601002565